# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

# КАРАРЫ

**2018 елның 18 апреле** **169N**

## Әлки муниципаль районында балаларны һәм яшьләрне патриотик тәрбияләү буенча Координацион совет төзү турында

Татарстан Республикасы Координацион советының патриотик тәрбия бирү буенча 2018 елның 6 марты беркетмәсендәге 5 пунктны үтәү йөзеннән һәм районда патриотик тәрбия системасын үстерү һәм модернизацияләү буенча нәтиҗәле эш башкару максатында, Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1.Әлки муниципаль районында балаларны һәм яшьләрне патриотик тәрбияләү буенча Координация Советы төзергә.

2.Расларга:

- Әлки муниципаль районында балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү буенча Координация Советы составын (1 нче кушымта).

- Әлки муниципаль районында балаларны һәм яшьләрне патриотик тәрбияләү буенча Координация Советы турындагы нигезләмә (2 нче кушымта).

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары М.А. Платоновага йөкләргә.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе: И.В. Юсупов

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль
районы Башкарма комитеты җитәкчесенең
_________________ __________N карарына
1 нче кушымта

## Әлки муниципаль районында балаларны һәм яшьләрне патриотик тәрбияләү буенча Координация Советы СОСТАВЫ

| | |
|---|---|
| Платонова М.А. | Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, рәис; |
| Савинов А.А. | "Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы мәгариф идарәсе" МКУ җитәкчесе, рәис урынбасары; |
| А.А.Гайфуллина | Әлки МР "Балалар иҗат йорты"ӨББМБО директоры, секретарь (килешү буенча); |
| Хәйруллина Г.Ф. | Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр сәясәте һәм спорт бүлеге белгече; |
| Захарова Н.П. | "Әлки муниципаль районы мәгариф идарәсе" МКУ җитәкчесе урынбасары; |
| Гайфуллина Р.А. | "Әлки районы мәдәният бүлеге" МКУ начальнигы; |
| Хәлиуллин Р.А. | Әлки МР ветераннар советы рәисе (килешү буенча); |
| Шәйхетдинов Р.С. | «Әлки районы Мәдәният йорты» МБУ директоры ( килешү буенча) ; |
| Лаврентьев В.П. | «Татарстан Республикасы хәрби комиссариатының Әлки районы буенча бүлеге начальнигы (килешү буенча); |
| А.Р. Низамиев | "Татмедиа" АҖ филиалы "Әлки хәбәрләре" газетасы редакциясе директоры(килешү буенча); |
| Ионова Л.Е. | "Алексеевск аграр көллияте" урта һөнәри белем бирү дәүләт аграр һөнәри белем бирү учреждениесе филиалы мөдире (килешү буенча). |

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль
районы Башкарма комитеты җитәкчесенең
_________________ _________N карарына
2 нче кушымта

## Әлки муниципаль районында балаларны һәм яшьләрне патриотик тәрбияләү буенча Координация Советы турында нигезләмә

### 1. Гомуми нигезләмәләр

Әлки муниципаль районында балаларны һәм яшьләрне патриотик тәрбияләү буенча Координация Советы (алга таба - Совет) Татарстан Республикасы Координацион советының патриотик тәрбия бирү буенча 2018 елның 6 марты беркетмәсендәге 5 пунктны үтәү йөзеннән һәм районда патриотик тәрбия системасын үстерү һәм модернизацияләү буенча нәтиҗәле эш башкару максатында төзелде.

1.1.Совет үз эшендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Конституцияләре, Федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы Президенты әмерләре һәм күрсәтмәләре, Әлки муниципаль районының норматив хокукый актлары һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.2.Совет үз эшен Әлки муниципаль районының җирле үзидарә органнары, учреждениеләр, предприятиеләр, ведомствога һәм оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр белән берлектә оештыра.

### 2. Советның төп максатлары һәм бурычлары

2.1. Совет эшчәнлегенең төп максаты - патриотик тәрбия системасын алга таба үстерү һәм камилләштерү, үсмерләрдә һәм яшьләрдә югары патриотик аң формалаштыру, Ватанга тугрылык булдыру.

2.2. Куелган максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:

- патриотик тәрбия белән шөгыльләнүче яшьләр учреждениеләрен, өстәмә белем бирү учреждениеләрен үстерү һәм модернизацияләү;

- мәгариф учреждениеләрендә патриотик тәрбиянең сыйфатын күтәрү;

- яшьләрне патриотик тәрбияләүнең норматив-хокукый һәм оештыру-методик базасын үстерү;

- иҗтимагый оешмаларны, мәгариф учреждениеләрен һәм хезмәт коллективларын патриотик тәрбияләүдә катнашуга җәлеп итү.

### 3. Советның төп функцияләре

Совет үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә:

3.1. Әлки муниципаль районында яшьләрне патриотик тәрбияләүнең өстенлекле юнәлешләрен, максатларын һәм бурычларын билгели.

3.2. Әлки муниципаль районында яшьләрне патриотик тәрбияләү эшен планлаштыра.

3.3. Яшьләрне патриотик тәрбияләү буенча теге яисә бу чараларны кабул итү кирәклеге турында билгеләнгән тәртиптә хәбәр итә.

3.4. Әлки муниципаль районында яшьләрне патриотик тәрбияләү эшенең торышы турында мәгълүмат-аналитик, белешмә материаллар һәм белешмәләр әзерли.

3.5. Яшьләрне патриотик тәрбияләү буенча органнар һәм учреждениеләр эшенең уңай тәҗрибәсен гомумиләштерә һәм тарата.

3.6. Массакүләм мәгълүмат чаралары, иҗтимагый берләшмәләр һәм башка оешмалар белән яшьләргә патриотик тәрбия бирү мәсьәләләре буенча хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра.

3.7. Совет карарларының үтәлешен тикшереп тора.

## 4. Совет вәкаләтләре

Совет хокуклы:

4.1. Әлки муниципаль районында яшьләрне патриотик тәрбияләү эшенең торышына комплекслы анализ ясарга.

4.2. Яшьләргә патриотик тәрбия бирү мәсьәләләре буенча барлык милек рәвешләрендәге оешма һәм учреждение җитәкчеләрен утырышларында тыңларга.

4.3. Яшьләрне патриотик тәрбияләүнең норматив-хокукый һәм оештыру-методик базасын үстерү, массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек итү буенча оешма һәм учреждение эшчәнлеген координацияләү.

4.4. Җирле үзидарә органнарыннан, вазыйфаи затлардан, иҗтимагый һәм башка оешмалардан аның эшчәнлеге өчен кирәкле мәгълүматны, документларны һәм материалларны соратып алырга.

4.5. Яшьләрне патриотик тәрбияләү буенча программалар проектлары буенча тәкъдимнәрне тиешле тәртиптә карарга һәм кертергә.

4.6. Яшьләргә патриотик тәрбиянең сыйфатын күтәрү буенча кирәкле оештыру чаралары күрергә.

4.7. Әлки муниципаль районы Башлыгын, Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесен Әлки муниципаль районында яшьләрне патриотик тәрбияләү буенча мәгълүмат белән таныштырырга.

## 5. Советның эш тәртибе

5.1. Совет рәис, рәис урынбасары, сәркатип һәм Совет әгъзалары составында төзелә.

5.2. Совет составы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең норматив-хокукый акты белән раслана.

5.3. Совет эшчәнлеген оештыру Совет эше планы нигезендә гамәлгә ашырыла. Эш планы агымдагы елга Совет әгъзаларыннан кергән тәкъдимнәр нигезендә төзелә, Совет утырышында карала һәм рәис тарафыннан раслана.

5.4. Совет утырышлары совет рәисе, ул булмаганда рәис урынбасары җитәкчелегендә кварталга кимендә бер тапкыр уздырыла яисә үз компетенциясенә керә торган мәсьәләләрне ашыгыч рәвештә карау кирәк булганда - кичектергесез. Советның кимендә өчтән ике әгъзасы булган очракта, Совет утырышы тулы хокуклы.

5.5. Совет рәисе Совет эшчәнлегенә җитәкчелек итә, исемлекне, аның утырышларында мәсьәләләрне карау срокларын һәм тәртибен билгели.

5.6. Совет сәркатибы:

- Совет эшен алып бара;

- Совет карарларын һәм алардан өземтәләрне рәсмиләштерә һәм җибәрә;

- Совет әгъзаларына чираттагы утырышны уздыру турында хәбәр итүне оештыра.

5.7. Совет карарлары утырышта катнашучы Совет әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигезләнгән очракта, Совет рәисенең тавышы хәлиткеч булып тора.

5.8. Совет әгъзалары мәсьәләләр буенча фикер алышканда һәм карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия. Кабул ителгән карар белән килешмәгән очракта, Советның һәр әгъзасы язма фикерен җиткерә һәм фикер беркетмәгә теркәлергә тиеш.

5.9. Совет карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм рәис яисә аның урынбасары һәм сәркатибы тарафыннан имзалана. Совет карарлары тәкъдим итү характерында.

5.10. Совет рәисе, ә ул булмаганда, рәис урынбасары чираттагы утырышны күчерә яки өстәмә рәвештә билгели.

5.11. Совет утырышында көн тәртибендәге аерым мәсьәләләр буенча чакырылган затларга фикер алышу өчен катнашу рөхсәт ителә.

"Әлки муниципаль районында балаларны һәм яшьләрне патриотик тәрбияләү буенча Координацион Совет булдыру турында" гамәлдәге редакция (Чыганак: "КОДЕКС" ИСС)